| ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА, АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ (Госалкогольинспекция Республики Татарстан) | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭТИЛ СПИРТЫ һӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ, ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ, СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ (Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе) |
|---|---|---|

# ПРИКАЗ

06.07.2018 № 12-07 /122

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен раслау турында

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затлар һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26 декабрь, 2008 ел, № 294-ФЗ Федераль законның 8.3 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Р.Ә.Арслановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Ж.Й. Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь
инспекциясенең « 06» июль,
2018 ел, № 12-07/122 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

1. Бу Тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе билгеләнә.

2. Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмә (алга таба – йөкләмә) дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) хәл кылуга вәкаләтле Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан раслана.

3. Йөкләмә түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

йөкләмәне бирү номеры һәм датасы;

йөкләмәне алучы вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда);

юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чарасының төре:

“Интернет” челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында алкогольле һәм спиртлы продукция турында мәгълүматлар урнаштыруда мәҗбүри таләпләр һәм тыюларның үтәлешен күзәтү;

юридик затның яки хосусый эшмәкәрнең эшчәнлеге турында мәгълүматларга анализ ясау юлы аша (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану нигезендә) (мәҗбүри таләпләрнең үтәлешенә контрольлек итү, закон нигезендә мондый мәгълүматлар тапшыру йөкләнгән затларның);

сәүдә объектларына һәм җәмәгать туклануы предприятиеләренә мониторинг нигезендә ваклап сатуда алкогольле продукциягә минималь бәяләр күләменә, алкогольле продукцияне ваклап сату вакыты, шартлары һәм урыннары буенча чикләүләрне үтәүгә карата мәҗбүри таләпләрнең үтәлешенә, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүдә алкогольле продукцияне ваклап сату таләпләренең, спиртлы продукцияне ваклап сату таләпләренең үтәлешен күзәтү;

юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган

контрольлек объектлары турында һәм (яки) юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек объектлары урнашкан территорияләр турында мәгълүматлар;

юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чараларын үткәрү чоры яки билгеле бер чорда берлектә эшләүне күздә тотмаган дәүләт контрольлеге чараларының ничә тапкыр (бер тапкыр, күп тапкыр) үткәрелүен күрсәтү;

Йөкләмәне төзегән вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары;

Йөкләмәне раслаган вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары һәм измасы.

4. Йөкләмә бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге форма буенча рәсмиләштерелә.

5.Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең контрольлек-инспекция бүлеге, бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, электрон рәвештә, юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чараларын үткәрүгә йөкләмәләрне, юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чараларын үткәрү нәтиҗәләренең учет журналын алып бара.

6. Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чараларын үткәрү нәтиҗәләре Тәртипкә №3 кушымта нигезендәге форма буенча бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм контрольлек чаралары тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срокта йөкләмәне раслаган затка җибәрелә.

7. Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чараларын үткәрүдә алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендә, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сату, спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозулар (административ җаваплылык күздә тотылган) ачыкланган очракта, вазыйфаи затлар тарафыннан административ хокук бозу турында эшне тикшерүне тәэмин итү чаралары күрелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибенә №1 кушымта

Форма

**Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе**

Раслыйм
Татарстан
Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе
җитәкчесе (җитәкче
урынбасары)
_____________ Ф.И.О
«____»
__________201__ ел

**Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрүгә йөкләмә**

№________ «___» ___________201 ел

«Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 26 декабрь, 2008 ел, № 294-ФЗ Федераль законның 8.3 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, боерам:

1. ____________________________________________

Контрольлек чарасын үткәрүгә вәкаләтле затның (затлар) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

үткәрергә____________________________________________

(контрольлек чарасының төрен күрсәтергә)

2. Карата: ____________________________________________

Контрольлек объекты һәм (яки) контрольлек объекты урнашкан территорияләр турында мәгълүматлар

3. Контрольлек чарасын үткәрү чоры ____________________

Тутырды

____________________ ____________________

вазыйфасы атамасы Ф.И.О.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибенә №2 кушымта

Форма

**Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрүгә йөкләмәләрнең учет журналы**

| № п/п | Йөкләмә не бирү датасы | Йөкләмә номеры | Юридик зат/хосусый эшмәкәр атамасы | ИНН | ОГРН | Эшчәнлекне хәл кылу урыны | Йөкләмәне алган затның Ф.И.О. | Йөкләмәне алган затның вазыйфасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

| Чараны башлау датасы | Чараны тәмамлау датасы | Чара төре | Контрольлек чаралары нәтиҗәләре турында мәгълүматлар | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |

Искәрмә:

- хуҗалык итүче субъектлар төркеменә карата юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрү очрагында 4, 5, 6 графалар тутырылмый, 7 графада эшчәнлек төре һәм (яки) аны хәл кылу урыны, эш режимы буенча һ.б. төркемнең уртаклык билгеләре күрсәтелә;

- берничә адрес буенча эшчәнлек алып баручы хуҗалык итүче субъектка карата юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрү очрагында 7 графада эшчәнлекне хәл кылу урыннарының саны күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары үткәрүгә йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибенә №3 кушымта

Форма

**Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек чараларын үткәрү турында бәяләмә**

«___» ___________201 ел

| Вазыйфасы | Инициаллары, фамилиясе |
|---|---|
| | |

нигезендә:

| |
|---|
| |

(контрольлек чарасын үткәрү турында йөкләмә номеры, датасы)

түбәндәгегә карата:

| Юридик зат (хосусый эшмәкәр) атамасы | ИНН | ОГРН |
|---|---|---|
| | | |

контрольлек чарасы үткәрелде

____________________________________________________________

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланды (ачыкланмады):

____________________________________________________________

Мҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү буенча күрелгән чаралар:

____________________________________________________________

| ____________________ | ______________ | ____________________ |
|---|---|---|
| контрольлек чарасын үткәргән зат вазыйфасы | имза | Ф.И.О. |

Искәрмә:

- хуҗалык итүче субъектлар төркеменә карата юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр белән берлектә эшләүне күздә тотмаган контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрү очрагында “Юридик зат (хосусый эшмәкәр) атамасы” графасында йөкләмәнең 2 пунктындагы мәгълүматлар күрсәтелә.